ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 ноября 2020 г. № 6175

2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 бүлекнең 13 пункты, Татарстан Республикасының «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Законы, Башкарма комитетның «Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү чаралары турында» 2007 елның 14 декабрендәге 4940 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары карамагындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга норматив чыгымнарны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктына туры китереп тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 20 ноябрендәге
6175 номерлы карарына
кушымта

2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
гомуми белем бирү оешмалары карамагындагы интернатларда
һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга
норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елына сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы карамагындагы интернат | шәһәр җирлеге | 92 851 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 139 227 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Бареева